# Бөҗәкләрнең күптөрлелеге.

Әтнә  муниципаль районы Түбән Көек гомуми урта белем бирү мәктәбенең  2 кв. кат. биология  укытучысы Шакирова Флера Гарифзяновна.

# Бөҗәкләрнең үзенчәлекле билгеләре нинди?



- Тәне 3 өлештән тора: баш, күкрәк, корсак.
- Күкрәге 3 сегменттан- алгы,урта, арткы күкрәктән тора.
- Хитин япма.
- Сулыш органнары – трахеялар.
- Кан әйләнеше системасы йомык түгел.
- Бүлеп чыгару органнары – мальпиги көпшәләре.

# Бөҗәкләрнең баш өлешендә нинди органнар урнашкан?



- ✔ Катлаулы күзләр;
- ✔ Мыеклар;
- ✔ Авыз органы.

# Бөҗәкләрдә ничә пар аяк?

- 3 пар
- Алар кая урнаша?
- Күкрәктә.
- Очучы бөҗәкләрдә канатлар кая урнаша?
- Күкрәктә.






## Хитин япма нинди роль үти?

- Тышкы скелет.



1. Имаго – ул:
1) гусеница ;
2) олы бөҗәк ;
3) курчак .
2. Нерв системасының тибы нинди ?
1) төенле ;
2) диффуз ;
3) көпшәсыман .
3. Бөҗәкләрнең йөрәк формасы нинди ?
1) көпшәсыман ;
2) капчыксыман ;
3) конуссыман .
4. Ашкайнату бизләренә керә :
1) төкерек бизләре ;
2) май тәнчеге ;
3) балавыз бизләре .

5. Барлык бөҗәкләр :

1) гермафродитлар ;
2) аерым җенесле ;
3) гермафродитлар һәм аерым җенеслеләр.

6. Бөҗәкләрнең кан әйләнеше системасы :

1) ачык ;
2) йомык ;
3) кан әйләнеше системасы юк .

7. Бөҗәкләр сулыйлар :

1) трахея аша ;
2) тән өслеге аша ;
3) трахея һәм тән өслеге аша .

8. Симбиотик организмнар , алар бер -берсенә :

1) файда китерә ;
2) зыян сала ;
3) нейтраль була .

# Беренчел канатсызлар, иң гади төзелешле бөҗәкләр.

- Дымлы җирдә: туфракта, таш астында, мүктә, базда яшәүчеләр.
- Зурлыклары бик кечкенә, кайберләренең зурлыклары 1мм. дан артмый.
- Беренчел канатсызлар туфрак ясауда катнашалар, аларга койрыгаяк, шикәр тәнкәтәне, камподея керә.






# Канатлы бөҗәкләр, югары төзелешлеләр.



# Бөҗәкләрнең отрядлары.

| Отрядлары | Билгеле төре | Вәкилләре |
|---|---|---|
| Көнлекче-ләр | 2000 | Сары көнлекче, гади көнлекче, буйлы көнлекче |
| Җилпәзәка-натлылар | 2000 | Соры җилпәзә канат, сары аяклы яз күбәләге, ишсез җилпәзәканат, соры канатлы яз күбәләге |
| Ярым каты-канатлылар | 30000 | Рапс кандаласы,  су кандаласы, кыр кандаласы |
| Тигез канатлылар | 30000 | Үлән бетләре, яфрак борчалары, акканатлар |
| Туры канатлылар | 20000 | Яшел чикерткә, күчмә саранча, гади чикерткә,  өй чикерткәсе |
| Каты канатлылар | 300000 | Май коңгызы, колорадо коңгызы, болан коңгыз, тирес коңгызы, каберче коңгыз |

| Отрядлары | Билгеле төре | Вәкилләре |
|---|---|---|
| Тәңкә канатлылар | 140000 | Кәбестә күбәләге, тут ефәкчесе, гади махаон, кычыткан күбәләге, адмирал |
| Элпә канатлылар | 300000 | Бал корты, шөпшә, кырмыска, җайдак бөҗәкләр, бызылдавыклар, мөгез койрыклар |
| Парканатлы-лар | 120000 | Чебеннәр, озын борыннар, бөгәлчәннәр, үгез кигәвене |
| Энә караклары. | 40000 | Яссы энә карагы, зәңгәр ук, нәфис ук. |

# Көнлекчеләр.



- Иң борынгы отряд, барлыгы 2 мең төре билгеле.
- Бер яки берничә тәүлек кенә яши.
- Озынлыклары 2 -40 мм.
- Авыз аппараты юк, корсак очында 3 койрык җепселе бар.

# Җилпәзәканатлылар.



- Барлыгы 2 мең төре билгеле.
- Метаморфоз тулы түгел,личинкалары агымсуда 1-4 ел яши.
- Башлары зур, мыеклары озын,авыз аппараты кимерүгә җайлашкан.
- Ике пар үтә күренмәле канатлары колачы 80 мм.



# Ярым катыканатлылар.

- Барлыгы 25-30 мең төре билгеле.
- Зурлыклары 0,7 -120 мм озынлыгындагы бөҗәкләр.
- Авыз аппараты кадагыч – суыргыч хортумнан тора.
- 2 пар канаты өстән гәүдәсен каплаган, алгы канатларының очы элпә, нигезе каты була.
- Ис бизләре бар.
- Тулы булмаган әверелешле бөҗәкләр.





# Тигезканатлылар.

- Барлыгы 30 меңнән артык төре билгеле.
- Озынлыклары  0,5 -65 мм.
- Авыз органнары чәнчеп суыруга җайлашкан
- Элпә канатлары үтә күренмәле.
- Тулы булмаган әверелешле бөҗәкләр.
- 5 асотрядка бүленәләр:яфрак борчалары,

үлән бетләре,акканатлар,цикадасыманнар, кокцидлар.

# Турыканатлылар.

- Барлыгы 20мең төре билгеле.
- Үсешләре тулы булмаган әверелешле.
- Күп кенә төрләренең канатлары юк.
- Авыз аппараты – кимерүгә, арткы аяклары - сикерүгә җайлашкан.




# Авыл хуҗалыгына зыян салучы турыканатлылар.

**Аю чикерткә.**



**Саранча.**






# Катыканатлылар.




- Барлыгы 300 мең төре билгеле.
- Зурлыклары 0,3мм дан алып 15см га кадәр.
- Авыз органнары кимерә торган.
- Ике төрле канатлары бар:каты канат һәм элпә канат.
- Тулы әверелешле бөҗәкләр, личинкаларының үсеше җирдә яки үзагачта уза, суда үсүчеләре дә бар.



# Урман, авыл хуҗалыгына зыян салучы катыканатлылар.





# Тәңкәканатлылар.

- Тулы әверелешле бөҗәкләр отряды.
- Барлыгы 140 мең гә якын төре билгеле.
- Авыз органнары  суыргыч хортумчыктан тора.
- Ике пар элпә канатлары бар.





# Тәнкәканатлыларның бер вәкиле



Көя күбәләге

# Элпә канатлылар.




- Барлыгы 300 мең төре билгеле.
- Зурлыклары 0,2 мм дан -5 см. га җитә.
- Вәкилләре – мөгезкойрыклар, бал котлары, шөпшәләр, җайдак бөҗәкләр.
- Үсемлекләрне яхшы серкәләндерүчеләр.






# Йортлаштырылган бөҗәкләр





# Термитлар- иң озак яшәүче бөҗәкләр.





# Парканатлылар.

- Барлыгы 120 мең төре билгеле.
- Авыз органнары чәнчү-суыру яки ялауга җайлашкан.
- Тулы әверелешле үсешле бөҗәкләр.
- Алгы канатлары гына үскән, арткы канатлары бызылдавыкка әйләнгән.
- Личинкаларның үсеше – суда, җирдә, тирес өемнәрендә.





# Бөҗәкләр – лабаратор хайваннар

**Парканатлылар отрядыннан җиләк-җимеш чебене дрозофила биологик тикшеренүләр объекты булып тора.**



# Энә караклары.



- Озынлыклары 1,4 – 120 мм, 4500 төре билгеле.
- Канат колачы 90 мм.
- Күзләре бик зур һәм катлаулы.
- Мыеклары кыска, челтәрсыман канатлы.
- Су буйларында ерткыч яшәү рәвеше алып баралар.
- Берничә төре Кызыл китапка кертелгән.

# Бөҗәкләрнең тышкы тирәлек шартларына җайлашулары.

**Кисәткеч һәм саклагыч төс**
***Камка, Колорадо коңгызы, Бал кортлары, Шөпшәләр***

**Саклаучы төс һәм гәүдәләренең формасы**
***Кычыткан күбәләге, таякчалар, кузгалак кандаласы***

**Бөҗәкләрнең гәүдәләренең төзелеше, төс һәм гадәтләренең җайлашу үзенчәлекләре** ***(тын позада калу)***
***Суфи чикерткәләр***

**Янагыч төс** ***(куркыныч позага керү)***
***Атучы бызылдавык***

**Мимикрия**
***Безелдәвек чебен, карышлавык күбәләгенең гусенницасы***



fotopak.ru


fotopak.ru


fotopak.ru










# Бөҗәкләрнең әһәмияте

| Кеше тормышында һәм табигатьтә әһәмияте | Вәкилләре |
| --- | --- |
| Чәчәкле үсемлекләрне серкәләндерүчеләр | Күбәләкләр, бал кортлары, төклетуралар |
| Туфракны органик, минераль матдәләргә баеталар. | Бөҗәкләрнең личинкалары |
| Умырткалы хайваннарга азык булып торалар (кошлар, рептилияләр, балыклар) | Парканатлылар(чебеннәр, озынборыннар)<br>Коңгызлар<br>Күбәләкләр |
| Биологик көрәш максатыннан файдаланылалар | Камка |



# Бөҗәкләрнең зарарлы яклары

| | |
|---|---|
| Үсемлекләргә зыян салучы паразитлар  | Турыканатлылар (чикерткәләр, саранчалар)<br>Кандалалар (корткыч ташбакачык кандала)<br>Күбәләкләр ( кәбестә күбәләге, алмагач көясе)<br>Коңгызлар  (колорада коңгызы, май коңгызы,кайры коңгыз) |
| Кеше һәм хайваннарның кан эчкеч паразитлары, авыру кузгатучы микроорганизмнарны күчерүчеләр  | Чебеннәр,бөгәлчәннәрнең личинкалары (мөгезле эре терлек тиресе)<br>Ат бөгәлчәннәре (атларның ашказаны)<br>Бетләр<br>Борчалар |

**Паразит бәҗәкләр китереп чыгарган авырулар**
**Бетләр – тимгелле тиф, кайтма тифны кузгату-чыларны күчерә**
**Борчалар –чума авыруын кузгатучыларны күчерә**
**Бизгәк озынборыны – бизгәк авыруын кузгату-чыларны күчерә.**
**Чебен 30 лап төр авыру кузгатучы микроорга-низмнарны күчерә. Дизентерия,корсак тифы, дифтерия,туберкулез шундыйлардан**
**Цеце чебене – йокы авыруын кузгатучыларны күчерә.**





# Тере барометрлар

- Умарта кортлары иртүк күпләп оча башласалар – көн аяз булыр.
- Көн аяз булып та кортлар күпләп умарталарына кайтып керә башласа – яшенле яңгыр көт.
- Коңгызлар очса – яңгыр явар.
- Кырмыскалар ояларын зур итеп төзесә, кыш суык һәм озын булыр.
- Бал кортларының очу тишекләре ачык калса – кыш җылы килер.

- Иң күп канат кагучы бөҗәк форсипомия озынборыны санала. Минутына 62760 тапкыр канат кага.
- Иң оста сикерүче булып борча санала, ул гәүдә озынлыгыннан 200 тапкыр ераккарак сикерә
- Баллы бөҗәкләр булып үлән бетләре тора
- Иң яңгыравыклы тавышлы бөҗәк цикада, тавышы 400 метрдан ишетелә.

# Бөҗәкләрне саклагыз!

- Кеше өчен кирәкле файдалы бөҗәкләр, беренче чиратта зарарлы буынтыгаяклыларны бетерүче ерткыч, паразит бөҗәкләр, үсемлекләрне серкәләндерүче файдалы продукт бирүче үсемлекләр сакланырга тиеш.



# Дәресне йомгаклау, нәтиҗә ясау

- “Чәчәк өздем – ул шиңде, күбәләк тоттым - үлде, шунда мин аңладым; табигатькә йөрәгең белән генә орынырга ярый икән”.





# Игътибарыгыз өчен рәхмәт